**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2023 елның 25 декабре** **148-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 31 гыйнварындагы 14-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне раслау турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы белән, 2023 елгның 14 декабрендәге җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен карап чыгып, 2023 елгның 15 декабрендәге җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап, Лаеш муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 31 гыйнварындагы 14-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне расларга (1 кушымта).

2. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И. П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район
Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы Т.П.Борһанова**